ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# 2015 елга Татарстан Республикасында хезмәт базары үзенчәлекләрен чагылдыра торган региональ коэффициентны билгеләү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 26 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге $227^{1}$ статьясы нигезендә 2015 елга Татарстан Республикасында хезмәт базары үзенчәлекләрен чагылдыра торган региональ коэффициентны 1,81 итеп билгеләргә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2015 елның 1 гыйнварыннан, ләкин рәсми басылып чыккан көненнән алып бер айдан да иртәрәк булмаган һәм физик затлар керемнәренә салым буенча чираттагы салым чорының 1 нче числосыннан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 27 ноябре
№ 108-ТРЗ